КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 июнь г.Казань № 498

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 13 август, 553 нче карары белән расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 13 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 10 октябрь, 732 нче; 2017 ел, 18 сентябрь, 675 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә, 2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«Җир кишәрлеген арендалау килешүе нигезендә стационар булмаган сәүдә объектлары 2015 елның 1 мартына кадәр төзелгән, гамәлдә булу вакыты чыкмаган

килешүләр буенча урнаштырыла.

Әлеге датага гамәлдә булган һәм стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруны күздә тоткан җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты чыккач, хуҗалык итүче субъект белән әлеге Тәртипнең 2.2.2 пунктчасы нигезендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин